**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района**
**Республики Татарстан**
**Совет города Арск**
**422000,г. Арск, площадь Советская , 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Арча шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

**« 30 » сентябрь 2022 ел** **№ 83**

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. Арча шәһәр Советының 2021 елның 27 апрелендәге 30 номерлы карары белән расланган «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1) 52 статьяның 1 өлешенең 3 пункты түбәндәгечә 12 һәм 13 нче пунктлар өстәргә:

- торак пункт җирләрендә урман хуҗалыгын, алар эчендә барлыкка килгән, урман бистәләре җирләрендә урнашкан, аларның чикләрен булдыру һәм үзгәртү, шулай ук урман хуҗалыгы урманчылыгы кагыйдәләрен эшләү һәм раслау турында карарлар кабул итә;

- торак пунктлар җирләрендә урнашкан урманнарга карата урман белән идарә итү эшчәнлеген алып бара.

2) 52 статьяның беренче өлешендәге 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 13 һәм 14 абзацлар өстәргә:

- үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү яисә аны Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата мәҗбүри таләпләр нигезендә капиталь төзелеш объектларын төзүнең рөхсәт ителгән иң чик параметрларына туры китерү турында карар кабул итә;

- күчемсез мөлкәтнең элек исәпкә алынган объектларының хокук ияләрен ачыклау буенча карарлар кабул итә һәм җирлек территориясендә күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертү өчен күчемсез мөлкәт объектларының хокук ияләре турында белешмәләр җибәрә.

2. Әлеге карарны ул кабул ителгәннән соң 15 көн эчендә уставларны теркәү һәм дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органының территориаль органына җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгына «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карарын уставларны теркәү һәм дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органының территориаль органыннан кергәннән соң җиде көн эчендә гражданнар күпләп җыела торган урыннарда һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгына әлеге карар халыкка җиткерелгәннән соң 10 көн эчендә у уставларны теркәү һәм дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органының территориаль органына үзгәрешләр һәм өстәмәләр чыганагы һәм рәсми игълан итү датасы турында белешмәләр җибәрергә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы,
шәһәр Советы рәисе

И.Г.Нуриев